**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.09.2026 № 305

Аксубаево

**2027 елга"Аксубай муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында**

"Россия Федерациясендә мәгариф турында" 29.12.2012 елгы 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы нигезендә, "Иҗтимагый хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы федераль закон белән, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының "Аксубай муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслауны кертү турында "10.12.2007 326 номерлы карары нигеендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2027 елга "Аксубай муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү мәктәп-интернатлары каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне тоту өчен норматив чыгымнар (муниципаль район исеме);

2. "Аксубай муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең Финанс бюджет палатасы бу карарның 1 пунктында расланган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарына туры китереп мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Бу карар рәсми рәвештә бастырылган көннән үз көченә керә һәм 2027 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Бу карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә (http://aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

5. Бу карарның үтәлешен контрольдә тоту Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе: С.Ю.Зайцев

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитетының
18.09.2026 № 305
карары белән расланган

**"Аксубай муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү мәктәп-интернатлары каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне асрауга**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| гомуми белем бирү оешмасы төре һәм күренеше | Территориаль урнашу | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елына сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | шәһәр җирлеге | 144690 |
| | авыл җирлеге | 145980 |
| Гомуми белем бирү мәктәп-интернаты | шәһәр җирлеге | 220493 |
| | авыл җирлеге | 225102 |